**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 152-18 «26» июль 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2022 елның 25 февралендәге 119-15 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең бердәм аттестация комиссиясен биләүгә конкурс уздыру буенча Бердәм комиссия турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең бердәм аттестация комиссиясен биләүгә конкурс уздыру буенча Бердәм комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль закон нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2022 елның 25 февралендәге 119-15 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең бердәм аттестация комиссиясен биләүгә конкурс уздыру буенча Бердәм комиссия турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәтнең бердәм аттестация комиссиясен биләүгә конкурс уздыру буенча Бердәм комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләрне кертергә:

1.1. сигезенче пунктта :

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт китабы һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, моңа хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклар керми;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм

Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: http:/ http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының Законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин